ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 август, 2024 ел № 35/15

Шәһәр Советының 2015 елның 28 декабрендәге 5/7 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 29 маендагы 185-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 23 декабрендәге 133-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2015 елның 28 декабрендәге 5/7 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибенә (Шәһәр Советының 2017 елның 20 июнендәге 17/9, 2017 елның 15 декабрендәге 21/12, 2018 елның 27 апрелендәге 24/9, 2022 елның 23 июнендәге 15/11 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 7 пунктта:

- 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) даими рәвештә йөртү тәртибен билгели һәм планлаштыру документларын раслый;»

- түбәндәге эчтәлектәге 4.1 пунктча өстәргә:

«4.1) муниципаль даими йөртү маршруты буенча йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм муниципаль маршрут картасы дубликатын бирү тәртибен билгели, муниципаль даими йөртү маршруты буенча йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм муниципаль маршрут картасы дубликатын бирә;»;

2) 33 пунктта:

- 1 пунктчада «Федераль законның 24 статьясындагы 10 өлешендә яисә әлеге Тәртипнең 42 пунктындагы 1, 2 яки 7 пунктларында» сүзләрен «Федераль законның 29 статьясы 1 өлешендәге 1, 2, 7, 9 яисә 11 пунктларында» сүзләренә алыштырырга;
- түбәндәге эчтәлектәге 3-4 пунктчалар өстәргә:

«3) юридик зат, шәхси эшмәкәр яисә гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы ачык конкурс үткәрү нәтиҗәсендә бирелгән даими рәвештә йөртү маршруты буенча йөртүне гамәлгә ашыру турында яңа таныклык нигезендә даими рәвештә йөртүне гамәлгә ашыра башлаганчы, Федераль законның 29 статьясындагы 3 өлеше нигезендә йөртүне гамәлгә ашыру бурычын үтәмәгән очракта;

4) Федераль законның 29 статьясындагы 7 өлешендә каралган хәлләр барлыкка килгәннән соң.»;

3) 34 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«34. Даими рәвештә йөртү маршруты йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә йөртү маршруты карталары аларны вакытына бер тапкыр тапшыру өчен нигез булган хәлләр килеп чыккан көннән башлап ачык конкурс уздырмыйча өч көн эчендә 180 көннән артмаган срокка, әгәр әлеге маршрут буенча йөртүне гамәлгә ашыру турында элек бирелгән таныклыкның гамәлдә булуын туктатып тору шундый хәл булса, күрсәтелгән таныклыкның гамәлдә булуын туктатып тору вакытына бирелә.»;

4) 36 пунктны көчен югалткан дип танырга;

5) 537 пунктта «һәм аны тутыру тәртибе» сүзләреннән соң «, аның ялганнан (охшатып ясаудан) саклануына карата таләпләрне, шулай ук даими рәвештә йөртү һәм багаж таш маршруты картасы турында белешмәләр булган электрон карталарга карата таләпләрне» сүзләрен өстәргә;

6) 38 пунктта:

- 6 пунктчада «әлеге маршрут буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы» сүзләрен «даими рәвештә йөртү маршрут картасы бирелгән» сүзләренә алыштырырга;

- 9 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«9) даими рәвештә йөртү маршруты картасының гамәлдә булу датасы һәм, әгәр ул чикләнгән вакытка бирелгән булса, аның гамәлдә булу срогы тәмамлану датасы»;

- 10 пунктчада «әлеге маршрутка карата даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрында» сүзләрен «Федераль законның 26 статьясы 1 өлешенең 12 һәм 13 пунктларында» сүзләренә алыштырырга;

7) 41 пунктта «биш көн дәвамында» сүзләрен «биш эш көне дәвамында» сүзләренә алыштырырга;

8) түбәндәге эчтәлектәге 41.1 пункт өстәргә:

«41.1 Даими рәвештә йөртү маршруты картасы аның гамәлдә булу срогы

озайтылуга бәйле рәвештә яңадан рәсмиләштерелгән очракта, юридик зат, шәхси эшмәкәр яисә гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы Башкарма комитетка аның гамәлдә булу срогы тәмамланырга биш көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итә.»;

9) 42 пунктта:

- 1 пунктчаны түбәндәге  редакциядә бәян итәргә:

«1) әлеге хокук бирелгән юридик зат, шәхси эшмәкәр яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның берсенең булса да пассажирлар һәм башка затларны автобусларда йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясен гамәлдән чыгару (гади ширкәт шартнамәсендә әлеге шартнамәнең калган катнашучылары арасындагы мөнәсәбәтләрдә саклануы каралган очрактан тыш)»;

- 3 пунктчаны түбәндәге  редакциядә бәян итәргә:

«3) юридик зат, шәхси эшмәкәр, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар даими рәвештә  йөртү маршруты буенча әлеге хокуктан баш тарту турындагы гаризалары нигезендә йөртүне туктаткан көн җитү. Әлеге гариза анда күрсәтелгән йөртүне ташуны туктату датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла»;

- 7 пунктчада  «яисә расписаниедә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны календарь атнасына өч көннән дә кимрәк вакыт эчендә башкару каралган очракта, бер календарь атнасыннан артыграк вакыт эчендә» сүзләрен өстәргә;

- түбәндәге эчтәлектәге  8-10 пунктчалар өстәргә:

«8) ачык конкурсны гамәлгә яраксыз дип тану турында суд карарының законлы көченә керүе;

9) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутын туктату турында Федераль законның 12 статьясындагы 3 өлешендә каралган карарның үз көченә керүе;

10) Башкарма комитетка җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә йөртү хокукы бирелгән шәхси эшмәкәрнең үлемен дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр керү (әлеге шәхси эшмәкәр башка катнашучылар арасындагы мөнәсәбәтләрдә әлеге шартнамәне саклап калу каралган гади ширкәт шартнамәсендә катнашучы булган очрактан тыш).»;

10) 43 пунктта «әлеге Тәртипнең 42 пунктының 1, 2, 4, 6 һәм 7 пунктчаларында» сүзләрен «әлеге Тәртипнең 42 пунктында» сүзләренә алыштырырга;

11) 44  пунктта «90 көннән соң» сүзләреннән соң  «, әгәр мондый таныклык вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан бирелгән очракта - ун көннән соң» сүзләрен өстәргә;

12) 46 пунктта:

- 1 пунктчаны көчен югалткан дип танырга;

-3, 4, 5 пунктчаларны түбәндәге  редакциядә бәян итәргә:

«3) гади ширкәт шартнамәсен туктату өчен Россия Федерациясе Гражданлык кодексында каралган нигезләрнең булуы (җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларга бирелгән очракта);

4) транспорт чараларын тукталыш пунктларыннан расписаниедә  билгеләнгән

вакыттан алдарак жибәреп регионара маршрут буенча бер ай эчендә ике һәм аннан да күбрәк рейслар башкару турында дәлилле шикаять булуы;

5) әлеге таныклык бирелгән юридик затны, шәхси эшмәкәрне, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның берсен генә булса да бер ел дәвамында Федераль законның 17 статьясындагы 4 өлешенең 1 һәм 5 пунктлары нигезендә Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән таләпләрне үтәмәгән өчен административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән административ җаваплылыкка тарту.»;

13) 47 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«47. Даими рәвештә йөртү һәм багаж тау маршруты карталарының гамәлдә булуы шушы маршрут буенча йөртүне гамәлгә ашыру турындагы таныклыкның гамәлдән чыгу көненнән, ә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу муниципаль контракт нигезендә яки концессия килешүе, яки муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырылган очракта, әлеге контрактның яки концессия килешүенең, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүнең гамәлдән чыгу көненнән туктатыла.»;

14) 48 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«48. Юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның берсенең генә булса да йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе гамәлдә булуы туктатылган очракта, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булуы, юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларга даими рәвештә йөртүне гамәлгә ашыру өчен бирелгән даими рәвештә йөртү маршруты карталарының гамәлдә булуы туктатыла. Гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның берсендә күрсәтелгән лицензиянең гамәлдә булуы туктатылган һәм мондый шартнамәдә гади ширкәт шартнамәсендә калган катнашучылар арасындагы мөнәсәбәтләрдә мондый шартнамәнең саклануын күздә тота торган шарт булган очракта, даими рәвештә йөртү маршруты буенча йөртүне ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булуы, гади ширкәт шартнамәсендә калган катнашучыларга бирелгән даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты карталарының гамәлдә булуы туктатылмый.».

2. Әлеге Карар 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме

Н.Г. Мәһдиев